**Республика Татарстан**
**Иляксазское сельское поселение**
**Сармановского муниципального**
**район**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районының Илексаз авыл**
**җирлеге**

---

РЕШЕНИЕ
№7

КАРАР
21.09.2020

Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының» Илексаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бердәм шәхси башкарма орган буларак яллаучы (эш бирүче) вәкиленә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен кире кайтарылмый торган нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 21 августындагы 14 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 1 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Гамәлдән чыгарырга:

Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Илексаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм шәхси башкарма орган буларак идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керүе өчен кире кайтарылмый торган нигездә катнашу рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 21 августындагы 14 номерлы карарны.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Илексаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә шәхси бердәм башкарма

орган сыйфатында кире кайтарылмый торган нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Илексаз авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 августындагы 14 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» карарны.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN.RU) һәм «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Илексаз авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Илексаз авыл җирлеге

Советы Рәисе Ф.М.Гильфанов